**Республика Татарстан**
**Рыбно-Слободский**
**муниципальный район**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Нижнетимерлекского сельского поселения**
422670, с. Верхний Тимерлек,
ул.Советская, д.4а
тел:8(84361)28-001,
э.почта Ntim.Rs@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422670, Югары Тегермәнлек авылы,
Совет урамы, 4а йорт

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР № 15**

Югары Тегермәнлек ав.2020 елның 17 марты

Югары Тегермәнлек Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге"муниципальберәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы "Җирле референдум турында" 23-ТРЗ номерлы Законы,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,2019 елның 8 ноябрендә ( узган гражданнар җыенында (Балык Бистәсе штп. өчен җирле референдумда) кабул ителгән №2 номерлы карарын тормышка ашыру максатында КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюның кушымта итеп бирелә торган Тәртибен расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Югары Тегермәнлек авылы (Балык Бистәсе штп.), Совет урамы, 72а йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтерына йөкләргә.

Балык Бистәсемуниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге
Башлыгы А.Н.Дмитриев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль
районы Түбән Тегермәлек авыл
җирлеге Башкарма
комитетының2020 елның
17 мартындагы 15 номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**“Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә**
**гражданнарның үзара салым акчаларын җыю**
**Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарныңүзарасалымакчаларынтүләү Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы “ Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан(белем алуның көндезге формасында укучыстудентлардан гайре, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артык була алмый)җирлереферендумда (гражданнарҗыенында) катнашуларынаһәмтавышбиргәндә алар тарафыннан белдерелгәнмөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә 2020 елның 31 мартына кадәрбашкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә бланкы (әлеге Тәртипкә кушымта) гражданнар игътибарына Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәгеhttp://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итүһәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (халыкка белдерү) ысулы белән, шулай ук кул куйдырып тапшыру юлы белән яисә почта аша юллап җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең лицевой счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр акча средстволарын физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган, почта переводларын (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәлек авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аркылы яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенчаТатарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү юлы белән башкарыла.

6. Түләү фактын раслаучы булып керем (приход) касса ордерының тамганамәсе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Гражданнарның билгеләнгән срокта кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
“ Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
җыю Тәртибенә КУШЫМТА

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы“ Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге”
Муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча
бер тапкыр түләнелә торган түләүне түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ №__________

ТүләүчененФ.И.А.и. ______________________________________________

Адрес: ________________________________________________________________________________________________

Сезгә 2020 елның 31 мартына кадәр________________________________________нигезендә _________________________________________чараларың тормышка ашыруга бер тапкыр түләнелә торган __________сумма күләмендәге түләүне түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: ____________________________________________________________

БИК (банкның таныклаучы коды) алучы банк _________________________________________

Сч. № ___________________________________________

Сч. № алучы__________________________________________________

ИНН ______________________________________________________

КПП ______________________________________________________________________________

КБК __________________ ОКАТО _____________________

Түләүнең билгеләнеше __________________________________________________________________________________________________________

Җитәкче _____________________________________________________________________________

М.У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

\- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы “ Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге”муниципальберәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнелә торган __________________сум күләмендәге түләүне түләү турында ХӘБӘРНАМӘ №_________

Түләүченең Ф.И.А.и. _________________________________________________________________________

Адрес:_______________________________________________________________________________________

Алдым “ ” ____________________, 20__ ел ________________________________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта ертып алына торган төпсә тутырыла һәм Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*